**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 ноябрь 2019 ел № 471

Ирекле тапшырылган законсыз сакланган яки табылган корал, сугыш припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы (2009 елның 19 мартындагы ред.) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында» карары, «Татарстан Республикасы территориясендә шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр, коралның, хәрби паспортларның, коралга патроннарның законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Законсыз саклanучы яки табылган корал, сугыш припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр өчен түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 июлендәге 305 номерлы «Корал, аның төп өлешләре, сугышчан припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч матдәләр һәм шартлаткыч җайланмалар ирекле рәвештә тапшырган өчен акча түләүне гамәлгә ашыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Районның Башкарма комитеты
Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин